Чистай муниципаль районы
Татар Сарсазы авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2021 елның 19 июле №13/3

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Татар Сарсазы авыл җирлегендә
җирдән файдалану һәм төзелеш
алып бару кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 июлендәге 11/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча комиссиянең 2021 елның 14 маендагы 2 номерлы бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Татар Сарсазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына, «Шәхси торак төзелеше зонасы» Ж1 территориаль зонасы чиген үзгәртү һәм Татар Сарсазы авылы, Үзәк ур., з/у 11 чикләрендә территориясен, шул исәптән кадастр номеры 16:42:170102:96 булган, 3068 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген «Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона» ОД1 төзелеш зонасына кертү өлешендә, үзгәрешләр кертергә (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны җирлек халкы күпләп җыела торган урыннарда игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татар Сарсазы авыл җирлеге
башлыгы Мусин С.С.

2021 елның 19 июлендәге 13/3 номерлы карарына
1 нче кушымта

Чистай муниципаль районы «Татар Сарсазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

